Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз өченче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

30 июль, 2020 ел № 283

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында законнарны гамәлгә ашыру барышы хакында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесенең Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы законнарны гамәлгә ашыру барышы турындагы мәгълүматын тыңлап, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы законнарны гамәлгә ашыруның барышы турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Җирле үзидарә органнарына, муниципаль учреждениеләргә, аларның җаваплы вазыйфаи затларына:

2.1 гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшне алга таба камилләштерү буенча чаралар күрергә һәм гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында законнарда билгеләнгән таләпләрнең тайпылышсыз үтәлешен, шул исәптән керүче мөрәҗәгатьләрне, аларны карау срокларын һәм нәтиҗәлелеген мәҗбүри теркәү өлешендә контрольне көчәйтергә;;

2.2. гражданнар мөрәҗәгатьләрен караганда башкару дисциплинасының дәрәҗәсен арттыру, кирәк булганда, бу өлкәдә законнарны бозуга юл куйган затларга карата хезмәт тикшерүләре уздыру;

2.3. кварталга бер тапкырдан да ким булмаган гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүгә системалы рәвештә анализ ясарга һәм гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турындагы законнарны бозу фактларын бетерү буенча чаралар күрергә;

2.4. гражданнарны кабул итүне оештыруның законнар белән каралган барлык рәвешләрен активрак кулланырга;

2.5. гражданнарга бирелә торган җавапларның сыйфатын күтәрү буенча өстәмә чаралар күрергә, мөрәҗәгать итүчеләрнең шәхси тормыш шартларын исәпкә алып, гражданнар мөрәҗәгатьләрен карап тикшерүгә якын килергә;

2.6. гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү өчен вәкаләтле белгечләрнең һөнәри квалификация дәрәҗәсен күтәрүне үз вакытында тәэмин итәргә;

2.7. гражданнарны шәхси кабул итүнең бердәм көне сәгатьләрендә район чараларын үткәрүне планлаштырмаска.

3. Әлеге карарны Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов